# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

“28” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2021 елнын 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ары авылында урамнарны чистарту, үлән чабу, иске агачларны кисү
- урамнарны яктырту һәм яктырткычлар сатып алу
- кое ремонтлау
- вак таш сатып алу һәм транспорт өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 188 (йоз сиксән сигез) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 114 (йөз ундүрт) кеше, бу 60,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 114 (йөз ундүрт) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ары авылында урамнарны чистарту, үлән чабу, иске агачларны кисү
- урамнарны яктырту һәм яктырткычлар сатып алу
- кое ремонтлау
- вак таш сатып алу һәм транспорт өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.